Хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында
ХӘБӘРНАМӘ

Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Олы Кайбыч авыл җирлеге, Чишмәле ур., 57 ж/к адресы буенча урнашкан, кадастр номеры 16:21:0110:532 булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1. Җир кишәрлеге буенча гавами кадастр картасыннан мәгълүмат;
2. Олы Кайбыч авыл җирлегенең шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;
3. Олы Кайбыч авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләреннән өземтә.

Проект буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе һәм сроклары:

1. Гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләнең асылы буенча чыгышлар.
2. Гавами тыңлауларда катнашучыларның сорауларын һәм тәкъдимнәрен карау.

Гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга барлык чыгышлар тәмамланганнан соң сораулар бирергә хокуклы. Сораулар һәм тәкъдимнәр язма рәвештә бирелә. Гавами тыңлаулар уздыру вакыты - 2025 елның 17 ноябреннән 2025 елның 25 ноябренә кадәр.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе: Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты, җир кишәрлеге урнашкан территориаль зона чикләрендә даими яшәүче гражданнар, шушы территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, шундый җир кишәрлекләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен (экспозицияләрен) ачу урыны һәм датасы: Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 нче кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге.

Экспозициягә (экспозицияләргә) бару мөмкинлеге булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат: 2025 елның 24 ноябрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, 2025 елның 25 ноябрендә 8.00 сәгатьтән 9.00 сәгатькә кадәр.

Проектка кагылышлы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше: Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегендә 2025 елның 17 ноябреннән 25 ноябренә кадәр 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр язма рәвештә кабул ителә.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат: 2025 елның 25 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й..

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм аңа карата мәгълүмати материаллар урнаштырылган рәсми сайт турында мәгълүмат: Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтының «Сайтка керүчеләр өчен файдалы мәгълүмат» бүлеге (http://kaybici.tatarstan.ru).

Әлеге хәбәрнамәне Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында «Сайтка керүчеләр өчен файдалы мәгълүмат» бүлегендә (http://kaybici.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) һәм Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й. адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк мәгълүмат стендында бастырырга.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Н. Макаров